**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2020 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, «Сатурн» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш конструкторы Гавариев Ренат Вильсор улына – коеп ясалган эшләнмәләрнең сыйфатын яхшырту һәм металл коючи калыпларын куллану мөмкинлекләрен арттыру максатларында металл калыпларга төсле металл эретмәләрен коюның технологик процессларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен;

2) техник фәннәр докторы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең техник физика кафедрасы доценты Гайсин Алмаз Фивзат улына – төрле физик үзенчәлекләргә ия эшләнмәләрнең, шул исәптән аддитив җитештерү технологияләрен кулланып эшләнгәннәрен дә кереп, катлаулы өслекләрен эшкәртүдә электролит-плазма технологияләрен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең төзелеш производствосы технологияләре кафедрасы мөдире Ибраһимов Руслан Габдерәшит улына – киң билгеләнештәге төзелеш композитлары әзерләү максатларында матдәләрнең үзлелеген арттыруда алдынгы технологияләрне кулланышка кертүнең фәнни нигезләрен һәм ысулларын эшләүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан , Кремль
2020 ел, 30 июнь
№ ПУ-376

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ